ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасын камилләштерү һәм нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеген Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Матбугат хезмәте итеп үзгәртергә.

2. “Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасын үзгәртү һәм штат санын оптимальләштерү турында” 2010 елның 22 октябрендәге 1205-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына (2013 елның 17 декабрендәге 3233-IV ДС номерлы, 2014 елның 23 октябрендәге 42-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче куышмтада:

“Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге, редакция-нәширлек секторын да кертеп” позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алыштырырга:

“Матбугат хезмәте”.

2) 2 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре:

– Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы раславына кертергә тиеш;

– Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты структурасына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының штат расписаниесенә һәм Татарстан

Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Административ регламентына үзгәрешләр әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе раславына кертергә, шулай ук законнар нигезендә кирәк булган оештыру-штат чаралары уздырырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2016 елның 4 марты
№ 1104-V ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2016 елның 4 мартындагы
1104-V ДС номерлы карарына
кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ СТРУКТУРАСЫ

